КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2025 ел, 21 март

г.Казань

№ 166

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 21 декабрендәге 3745-б номерлы боерыгы белән расланган 2026 елга кадәр контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген камилләштерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы («юл картасы») чаралары планын раслау турында» 2017 ел, 28 февраль, 121 нче карары белән расланган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 21 декабрендәге 3745-б номерлы боерыгы белән расланган 2026 елга кадәр контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген камилләштерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планына («юл картасы»на) кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 21 декабрендәге 3745-б номерлы боерыгы белән расланган 2026 елга кадәр контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген камилләштерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы («юл картасы») чаралары планын раслау турында» 2017 ел, 28 февраль, 121 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 20 гыйнвар, 14 нче, 2020 ел, 25 сентябрь, 867 нче, 2020 ел, 1 декабрь, 1081 нче, 2021 ел, 26 февраль, 104 нче, 2021 ел, 16 август, 723 нче, 2021 ел, 23 октябрь, 1000 нче, 2022 ел, 19 май, 473 нче, 2022 ел, 28 октябрь, 1148 нче, 2023 ел, 30 гыйнвар, 74 нче, 2023 ел, 6 ноябрь, 1425 нче, 2024 ел, 12 сентябрь,

770 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 21 декабрендәге 3745-б номерлы боерыгы белән расланган 2026 елга кадәр контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген камилләштерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планына («юл картасы»на) кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 21 декабрендәге 3745-б номерлы боерыгы белән расланган 2026 елга кадәр контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген камилләштерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планына («юл картасына») кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 21 март, 166 нчы карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре исемлеге

| Т/с | Контроль (күзәтчелек) төрләре | Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы исеме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | | |
| 1. | Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе |
| 2. | Алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне (шул исәптән энергетик) сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 3. | Россия Федерациясе Музей фондының торышына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| 4. | Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының торышы, аларны карап тоту, саклау, куллану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклауга төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты |
| 5. | Төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы |
| 6. | Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 7. | Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| 8. | Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 9. | Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| 10. | Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 11. | Махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |
| 12. | Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе |
| 13. | Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 14. | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә тарифларны җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты |
| 15. | Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 16. | Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә тарифларны җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 17. | Табигый монополияләр өлкәләрендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 18. | Тереклек өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләр куллануга төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 19. | Электр энергетикасындагы бәяләр (тарифлар) белән идарә ителә торган дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 20. | Газ белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт җайга сала торган бәяләрне (тарифларны) билгеләү | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | һәм (яисә) куллану өчен төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 21. | Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен һәм кәгазь чыганакта диагностика картасы дубликатын биргән өчен түләү күләмнәрен үтәгән өчен төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 22. | Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе |
| 23. | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруны төбәк дәүләт лицензия контроле | |
| 24. | Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеше күзәтчелеге инспекциясе |
| 25. | Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булуы туктатып торылган аерым муниципаль берәмлекләрдә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 26. | «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булуы туктатылган | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | кайбер муниципаль берәмлекләрдә торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 27. | Архив эше турындагы законнарның үтәлешенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты |
| 28. | Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы |
| 29. | Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |
| 30. | Балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары реестрында торучы балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары турында мәгълүматларның дөреслеге, актуальлеге һәм тулылыгы өчен төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| 31. | Туристлык индустриясе өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты |
| Федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), аны гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган | | |
| 1. | Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлегенә федераль дәүләт лицензия контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 2. | Мәгариф өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 3. | Урман фонды җирләрендә федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 4. | Федераль дәүләт аучылык контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |
| 5. | Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 6. | Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының торышына, аларны тотуга, саклап калуга, алардан файдалануга, аларны | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 7. | Махсус юл транспортын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм махсус юл транспортынннан файдалану кагыйдәләре үтәлешенә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе |